



*14 февральдә лицей китапханәсендә бөек татар галиме, энциклопедист, педагог һәм мәгърифәтче Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулу уңаеннан "Каюм Насыйри мирасы" дип аталган темага ачык дәрес үтте. Чарада китапханә мөдире 3, 4 сыйныф укучыларын К.Насыйриның тормыш юлы һәм фәнни эшчәнлеге белән таныштырды. Галим-мәгърифәтче, педагог һәм язучы Каюм Насыйриның  халыкны белемле итү, аның телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен үстерү өлкәсендә зур эш башкаруын, аң-белемне ана телендә бирүне, укымышлы кеше булу өчен үз телен белүне хуплавын сөйләде. Каюм Насыйриның "Шифалы үләннәр" китабы нигезендә дару үләннәреннән күргәзмә оештырылган иде. Чарада катнашучылар бу хакта фикерләре белән уртаклаштылар. Соңыннан укучылар бөек галим иясенең "Китаб-әт-тәрбия"сеннән өзекләр укыдылар.*

*Чара матур бер хатирә булып укучылар күңелендә озак сакланыр!*


Каюм Насыйри
(1825-1902)
КАЮМ НАСЫЙРИ
ШИФАЛЫ
ҮЛӘННӘР
ХӘВАСЕ НӘБАТАТ
Татар дөньясы

